КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2018 ел, 10 сентябрь г.Казань № 766

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте белән идарә итү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 31 декабрь, 1140 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте белән идарә итү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 31 декабрь, 1140 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2014 ел, 24 май, 349 нчы, 2015 ел, 30 март, 198 нче, 2016 ел, 24 март, 165 нче, 2017 ел, 22 апрель, 238 нче; 2018 ел, 9 апрель, 224 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарның исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте белән идарә итү» дәүләт программасын раслау турында»;

карарның 1 нче пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Бу карарга теркәлгән «2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте белән идарә итү» дәүләт программасын (алга таба – Программа) расларга»;

әлеге карар белән расланган «2014 – 2020 елларга Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте белән идарә итү» дәүләт программасына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

Программа исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте белән идарә итү» дәүләт программасы»;

Программа паспортында:

«Программаның исеме» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Программаның исеме | «2014 – 2021 елларга Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте белән идарә итү» (алга таба – Программа)»; |

«Программаны тормышка ашыру вакытлары һәм этаплары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Программаны тормышка ашыру вакытлары һәм этаплары | 2014 – 2021 еллар»; |

«Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләмнәре» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | |
|---|---|
| «Еллар һәм чыганаклар буенча бүлеп, Программаны финанслау күләмнәре» | Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән Программаны финанслауның гомуми күләме 9 188,65 млн.сум тәшкил итә, шул исәптән еллар буенча бүлеп:<br>2014 ел – 1 016,48 млн.сум;<br>2015 ел – 3 376,21 млн.сум;<br>2016 ел – 1 886,84 млн.сум;<br>2017 ел – 1 415,82 млн.сум;<br>2018 ел – 938,36 млн.сум;<br>2019 ел – 181,82 млн.сум;<br>2020 ел – 186,56 млн.сум;<br>2021 ел – 186,56 млн.сум.<br>Программаны тормышка ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан бүлеп бирелә торган финанслау күләме Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законы нигезендә ел саен тәгаенләнәчәк»; |

«Еллар буенча бүлеп, Программаның максатларын һәм бурычларын тормышка ашырудан көтелә торган соңгы нәтиҗәләр (нәтиҗәләрне бәяләү индикаторлары) һәм Программаның бюджет нәтиҗәлелеге күрсәткечләре» юлында «2020 елга» сүзләрен «2021 елга» сүзләренә алыштырырга.

Программаның II бүлегендә:

егерме тугызынчы абзацта «2020 елга» сүзләрен «2021 елга» сүзләренә алыштырырга.

утыз сигезенче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Программаны тормышка ашыру вакыты – 2014 – 2021 еллар.»;

Программаның III бүлеген түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«III. Программаның ресурслар белән тәэмин ителешен нигезләү

Татарстан Республикасы бюджеты акчасы исәбеннән Программаны финанслауның гомуми күләме 9 188,65 млн.сум тәшкил итә, шул исәптән еллар буенча бүлеп:

2014 ел – 1 016,48 млн.сум;
2015 ел – 3 376,21 млн.сум;
2016 ел – 1 886,84 млн.сум;

2017 ел – 1 415,82 млн.сум;
2018 ел – 938,36 млн.сум;
2019 ел – 181,82 млн.сум;
2020 ел – 186,56 млн.сум;
2021 ел – 186,56 млн.сум.

Программаны тормышка ашыру өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан бүлеп бирелә торган финанслау күләме Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законы нигезендә ел саен тәгаенләнәчәк.»;

Программаның V бүлегендә:

унтугызынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Бюджет нәтиҗәлелеге өлешендә Татарстан Республикасы бюджетының дәүләт мөлкәтен реализацияләү һәм файдаланудан, акцияләрне сатудан кергән акчадан салым булмаган керемнәре түбәндәге күләмнәрдә фаразлана:

| Ел | Дәүләт мөлкәтен реализацияләү һәм файдаланудан, акцияләрне сатудан кергән акчадан Татарстан Республикасы бюджеты керемнәре |
|---|---|
| 2014 | 799,1 |
| 2015 | 917,9 |
| 2016 | 758,4 |
| 2017 | 2 035,5 |
| 2018 | 753,9 |
| 2019 | 384,9 |
| 2020 | 436,4 |
| 2021 | 421,3 |
| Барлыгы | 6 507,4»; |

егерме икенче абзацта «2020 елга – 4,4 млрд.сум» сүзләрен «2021 елга – 4,5 млрд.сум» сүзләренә алыштырырга;

кырык бишенче абзацта «якынча 20 дәүләт унитар предприятиесе» сүзләрен «якынча 13 дәүләт унитар предприятиесе» сүзләренә алыштырырга;

Программага теркәлгән кушымтаны (карарга теркәлә) яңа редакциядә бәян итәргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин